ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.07.2023 Сарсак-Умга авылы № 16

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Сарсак-Умга авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә этләрне йөртү һәм (яки) өйрәтү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының 15.09.2018 елның 46-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының " Сарсак-Умга авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 2.12.16.2 пункты, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2023 елның 15 маендагы 02-06-2023/Прдп 207 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге территориясендә этләрне йөртү һәм (яки)өйрәтү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

*1) Сарсак-Умга авылының төньяк-көнчыгыш өлеше Яшьләр урамыннан 50 м ераклыкта;*

*2) Сарсак-Умга авылының көньяк-көнбатыш өлеше Ворошилов урамыннан 50 м ераклыкта.*

2. Этләрне йөрткәндә һәм (яки) өйрәткәндә түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

1) Автомобиль юлының йөрү өлеше киселгәндә, күпфатирлы йортларның гомуми файдаланудагы биналарында, мондый йортларның ишегалларында,

балалар һәм спорт мәйданчыкларында хайванның ирекле, контрольсез йөрү мөмкинлеген юкка чыгарырга;

2) хайваннарның тормыш эшчәнлеге продуктларын гомуми файдаланудагы урыннарда һәм территорияләрдә җыештыруны тәэмин итәргә;

3) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитетының әлеге карары белән рөхсәт ителгән урыннардан читтә хайванның йөрүенә юл куймаска

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Т.С. Николаева